| Каралган | Килешенгән | Раслыйм |
|---|---|---|
| МБ җитәкчесе<br>_____ /Нәҗметдинова Л.Ә./<br>Беркетмә № 1<br>«25»август 2014 ел. | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ<br>_____ /Сәгъдиева Г.Ф./<br>«25»август 2014 ел. | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең директоры<br>_____ / Әхмәтшина Л.М./<br>Приказ № 94<br>«27»август 2014 ел. |

Уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән ТГБМ” ГББМУ

Әхмәтшина Лариса Михаил кызы, югары категорияле укытучы

татар теле, 9 нчы сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № 1
« 25 »август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

## Аңлатма язуы

**9 нчы сыйныфта** татар теленнән эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. 2012 нче елның 29 нчы декабреннән гамәлгә кергән“РФ дә Мәгариф турында”273 нче федераль кануны (“Закон об образовании в РФ” )
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы кануны.
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы.
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа.
5. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5-9 нчы сыйныфлар) / Төзүче-авторлар – М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов,– Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
6. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы 17291/14 №лы хаты (04.09.2014.)
7. ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы (2012 нче ел)
8. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның 2014/15 нче уку елына уку-укыту планнары (25.08.2014 нче ел датасы белән чыгарылган 91 нче № лы боерык);
9. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның уку фәннәреннән эш программасын төзү турындагы локаль акты (Положение о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) МБОУ «Новомелькенская ООШ» Мензелинского муниципального района РТ)

**Ана (татар) телен укытуның гомуми белем бирү программасында урыны:**

Гомуми төп белем бирү мәктәбендә ана телен өйрәтү телнең төрле катламнарына караган теоретик материалны өйрәтү белән бергә, татар теленең сүзлек байлыгын, мәгънәви һәм кулланылыш үзенчәлекләрен камил куллана белергә, ана теленең сыгылмалылыгын, аралашу процессында ачыла торган нечкәлекләрен, үзенчәлекләрен өйрәтүне дә күздә тота. Татар мәктәбе буларак татар теленнән белем бирүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм иң мөһиме — аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә өйрәтүне, заманча технологияләрне файдаланып, телнең психолингвистик үзенчәлекләренә, мәдәният белән бәйләнешенә игътибар бирүне дә таләп итә. Бүгенге җәмгыятьтә барган үзгәрешләр ана телен укытуга яңа таләпләр куя. Беренче чиратта, ана теле дәресләре тел системасын, аның үзенчәлекләрен күзаллаган, милли үзаңга ия, милли менталитетны һәм психологияне аңлаган, заман таләпләренә җавап бирерлек күпкырлы шәхесләр тәрбияләүгә юнәлгән булырга тиеш. Әлеге таләпләр уку-укыту методикасын яңартуны, белем бирүгә яңача якын килүне, хәзерге җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең бала психологиясенә тәэсирен аңлауны һәм шулар нигезендә укыту эчтәлеген яңарту, уку-укытуның яңача алымнарын эзләү бурычын куя. Эш прогаммасында гомуми төп белем бирү эшчәнлегенең формалашуы һәм үсеше программасында каралган төп идеяләр игътибарга алынган, татар мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында ана теле укытуның гомуми үрнәк программасының эчтәлегендә каралган материалның дәвамчанлыгы һәм башлангыч белем бирү баскычында формалаша башлаган күнекмәләрнең үсеше каралган. Шулай ук төп белем бирү баскычында үзләштерелергә тиешле материалның эчтәлеге, укучыларның яшь һәм психологик үзенчәлекләре дә исәпкә алынган.

Төп мәктәптә ана теле курсы белем бирү процессының предметара һәм аерым предмет эчендә куелган максатларын тормышка ашыруга йөз тота. Шуны искә алып, программада татар теленә өйрәтү эчтәлеге *компетентлы якын килү принцибына* нигезләнде. Әлеге принцип IX сыйныфта коммуникатив, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләрне формалаштырырга һәм үстерергә ярдәм итә.

Туган телнең граматик төзелешен, аның нечкәлекләрен һәм кулланылыш үзенчәлекләрен аралашу процессында дөрес кулланырга өйрәтү әлеге икенче баскычта, шул исәптән 9 нчы сыйныфта да төп максатлардан санала. Татарстан Республикасында татар теленең дәүләт теле булуы, аның татар халкының рухи мирасын буыннан-буынга җиткерү чарасы икәнлеге, кешеләренең үзара аралашуында, шәхеснең формалашуында һәм дөньяны танып белүендә төп чыганак булуын укучыларга җиткерү бурычы да **9 нчы сыйныфта** да үтәлә. Бу сыйныфта татар

теленең төп эчтәлеге өйрәнелә, укучыларга татар теле буенча системалы, фәнни яктан ныклы белем бирелә, уку эшчәнлегенең төп төрләре формалаша һәм үстерелә.

Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде. Милләтара мөнәсәбәтләрне якынлаштыручы, җайга салучы чара буларак та аның мөмкинлекләре үсте. Укучыларда **лингвистик** (тел), **аралашу** (коммуникатив), **этнокультура өлкәсенә караган** (культурологик) **компетенцияләр** булдыру татар мәктәбендә татар теленә өйрәтү алыштыргысыз өлешен тәшкил итә.

**Лингвистик компетенция**

Тел система һәм иҗтимагый-мәдәни күренеш буларак өйрәнелә. Татар теленең барлык бүлекләре буенча үзләштерергә тиешле түбәндәге төп теоретик мәгълүматлар карала:

1) татар теленең иҗтимагый-мәдәни роле; татар милли әдәби теле һәм аның орфографик һәм орфоэпик нормалары; телнең фонетик системасы һәм аның закончалыклары, комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләре; татар телендә аваз һәм фонема, транскрипция; иҗек, татар теленең иҗек калыплары; басым һәм аның төрләре; интонация һәм аның компонентлары;

2) сүз, аның лексик мәгънәсе; сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләре; татар теленең сүзлек составы, аның ачык система тәшкил итүе; сүзләрне килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм активлыгы ягыннан төркемләү; фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънә үзенчәлекләре; лексикография;

3) сүзләрнең мәгънәле кисәкләре, аларның төрләре, сүз ясалыш ысуллары;

4) мөстәкыйль сүз төркемнәренең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәренең грамматик үзенчәлекләре, сөйләмдә кулланылышлары;

5) сүзтезмә һәм җөмлә, сүзләр һәм җөмләләр арасында бәйләнеш төрләре; җөмләнең аерымланган кисәкләре; җөмләләрне төркемләү принциплары; кушма җөмлә һәм аларның мәгънә ягыннан төрләре; туры һәм кыек сөйләм; текст, аның төзелеше; татар телендә тыныш билгеләре;

6) функциональ стильләр, аларның лексик-грамматик үзенчәлекләре.

**Лингвистик компетенция** (укуыларның ана теленнән мәгълүматлылыгы) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализ һ.б.ш темаларны түбәндәге темалар үз эченә ала:

Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны.

Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле. Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә.

Татар теленең үсештә булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгәрешләр. Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

**Коммуникатив компетенция**

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) үзләштерелә. Беренче этапта укучылар укылган яки тыңланган текстның темасы, төзелеше һәм төп фикерен, жанрын ачыклый, текст буенча әңгәмә үткәрә, үз фикерен дәлилли, телнең орфографик һәм орфоэпик, лексик, морфологик, синтаксик нормаларын саклап, эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып, телдән яки язмача җиткерә. Телнең әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга диалогик һәм монологик сөйләм оештыра. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзи. Төрле типтагы язма эшләр, шул исәптән компьютер технологияләре кулланып, укучы диктант, изложение, сочинение һ.б. эшләр башкара. Татар сөйләм әдәбе нормаларын дөрес һәм урынлы куллана.

**Аралашу** (коммуникатив) **компетенциясе** ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру кебек эшчәнлекләр түбәндәге темаларда яктыртыла: Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле.

Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.

Татар әдәби теле һәм аның нормалары турында төшенчә.

Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.

Укуның төрле төрләрен (танышу, өйрәнү һ.б.) үзләштерү. Уку китаплары, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б. чаралар белән эшләү алымнарын үзләштерү.

Иҗтимагый-мәдәнии, әхлакый, көнкүреш, уку темаларына бәйле булган монологтк һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү.

Текстның эчтәлеген кыскача , тулы яки сайлап алып сөйләү. Диктантлар, изложениеләр һәм сочинениеләр язу. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү: бәяләмә, аннотация, хат, ышаныч кәгазе, гариза, тезис, конспект һ.б.ш.

**Этномәдәни компетенция**

Укучыларга телнең милли мәдәниятне чагылдыру формасы булуы аңлатыла. Тел чаралары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләре өйрәтелә. Тәкъдим ителгән текстлардан халык авыз иҗаты үрнәкләрен, тарихи лексиканы аеру, аларның төрләрен һәм мәгънәләрен ачыклау. Татар милләтенең дөньяны танып белүен чагылдырган төп төшенчәләр, аларның сүздә, сүз мәгънәсендә чагылыш үзенчәлекләре өйрәтелә. Татар халык иҗаты үрнәкләрендә сүзнең кулланылышы, төшенчәләрне бирү мөмкинлекләре анализлана.

Шулай итеп, татар мәктәбе өчен ана телен укыту программасы эшлекле якын килүгә нигезләнә һәм аны тормышка ашыру өчен кирәкле алшартларны күзаллап төзелә. Укучыларның сөйләм эшчәнлеге үсеше һәм шәхси үсеш-үзгәреше югарыда саналган компетенцияләрдә ачык чагыла: коммуникатив компетенция төркемендә өйрәнелә торган тел материалы аралашу күнекмәләре булдыру максатын күздә тотып бирелә, лингвистик компетенция төркемендә аралашу өчен кирәкле тел материалының төзелеше, структурасы, эчтәлеге тәкъдим ителә, социомәдәникомпетенция төркемендә тел материалы халыкның мәдәниятен һәм тарихын чагылдыра торган билге буларак бирелә.

**Этнокультура өлкәсенә караган** (культурологик) **компетенция,** ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләмгә милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

**Эш программасының төп максаты:**

**9 нчы сыйныфта** татар телен укыту ана телен укытуның икенче баскычына (5-9 нчы сыйныфлар) туры килә. **Моның төп максаты** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Беренче баскычта күрсәтелгән максатка ирешүне тагын да камилләштерү, ягъни укучыларның тулы грамоталылыгына ирешү, сөйләмә һәм язма тел культурасын күтәрү.
2. Татар теле фәне нигезендә эзлекле белем бирү; телне гамәли куллану культурасын булдыруга ныклы нигез салу.
3. Милли горурлык тәрбияләү, тел аркылы үз халкыңның тарихын, гореф-гадәтләрен, психологиясен тирәнрәк үзләштерү.
4. Укучыларның башлангыч мәктәптә һәм 5 нче сыйныфта татар теленнән фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, морфологик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү;
5. Укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилли белергә күнектерү;
6. Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложенияләр яздырыла.

Әлеге максатларны коммуникатив, фәнни һәм тәрбияви яктан карасак, алар түбәндәгечә:

1) *коммуникатив максат*: укучыларны ана телендә иркен сөйләшергә һәм аралашырга, логик эзлекле итеп уйлый белергә, фикерне төгәл, ачык итеп җиткерә белергә өйрәтү; туган телнең аралашуда, рухи-әхлакый нормалар формалашуда һәм дөньяны танып белүдә төп чара булуын, аның эстетик кыйммәтен аңлату;

2) *фәнни максат*: татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз төзелеше һәм ясалышы, грамматик, стилистик нигезләре турында теоретик мәгълүмат бирү;

3) *тәрбияви максат*: туган телгә ихтирам һәм ярату хисләре тәрбияләү; укучыларда гуманлылык хисләрен тәрбияләү; әти-әниләргә, инвалидларга, ятим балаларга шәфкатьлелек хисләрен тәрбияләү; матурлыкны күрә, тоя белергә өйрәтү; туган як табигатен яратырга өйрәтү; туган илең белән горурлану, аны саклау; сәламәт яшәүнең бер төре булган спорт белән кызыксындыру һ.б.

**Укытуның икенче баскычында татар теле фәнен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр**:

Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган **бурычлар**:

●укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз ясалыш, грамматик, стилистик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү һәм телне тулы бер система буларак күзаллауны булдыру;

●укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;

●телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;

● язма һәм сөйләмә тел чараларын дөрес куллана белергә, аларны чагыштыра һәм кирәклесен сайлый, бәяли белергә өйрәтү;

●татар әдәби теле нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;

●телнеӊ милли мәдәниятнеӊ чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аӊлату; татар теленеӊ милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү;

●татар халкының этник төркемнәре һәм диалектлары, төрки телләр, татар теле, татар язуы, татар халкының рухи, әхлакый, мәдәни мирасы турында мәгълүмат бирү;

●татар телен иҗтимагый күренеш буларак аӊлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, аралаша-аӊлаша белү;

●тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, рус теле белән чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;

●текст һәм Интернет, электрон уку-укыту ресурслары, башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм шуны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;

●укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү;

укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аӊлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

**9 нчы сыйныф өчен төзелгән эш программасының бурычлары:**

Бу юнәлештә эшне уӊышлы алып бару өчен, түбәндәге **бурычлар** куела:

1. “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында”гы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру
2. Татар теле фәненеӊ төп бүлекләре һәм категорияләре, татар теленеӊ төрләре һәм аларның үсеш юллары белән таныштыру.
3. Укучыларда татарча әйтмә һәм язма сөйләм культурасы булдыруны татарча сөйләү, уку, язу күнекмәләрен көндәлек ихтыяҗга әйләндерү аша тормышка ашыру.
4. Дәреслекләрдә бирелгән төп төшенчәләрне, терминнарны һәм билгеләмә-кагыйдәләрне укучыларның аӊлы рәвештә үзләштерүенә ирешү.

**9 нчы сыйныфка килгәндә уку елы башында укучылар түбәндәге белем-күнекмәләргә ия:**

1. Туры сөйләмне үз сөйләмеңдә файдалана белү, чит кеше сүзләрен диалог яки монолог формасында бирә алу.Туры сөйләмгә бәйле тыныш билгеләрен дөрес куя,куелганнарыны аңлатма бирә белү;

2. Кушма җөмләләрдән тиешнчә файдалану, аларның төрле төрләрен төзү, таләп ителгән мисал китерү.

3.Җөмләгә һәм текстка өлешчә яки тулы грамматик анализ ясый белү, кушма җөмлә компонентлары арасына тиешле тыныш билгеләрен кую, аларны дәлилләү.

4. Төрле төзелештәге кушма җөмлә өлешләрен сөйләмдә тиешле интонация белән уку;

- тема эчендә диалог һәм монолог формаларында сөйли һәм яза белү;

5. Сыйфатлама, модальлек, эмоциональлек элементларын, стиль үзенчәлекләрен кулланып, укыту һәм тәрбия максатларына уңай җавап бирерлек темаларга сочинение һәм изложение язу.

6. Язмаларны камилләштерү (тулыландыру, төзәтмәләр кертү);

7. Әсәргә яки аның бер өлешенә рецензия язу;

8. Җыелыш яки берәр утырышның беркетмәсен яза белү;

9. Мәктәп программасы таләп иткән күләмдә җөмлә составындагы сүзләргә фонетик, морфологик, грамматик анализ ясау, кушма җөмләләрне бер төрдән икенче төргә үзгәртә белү; кушма җөмләнең схемасын, төрен, иярчен җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше ягыннан төрен,иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитак һәм синтетик чараларны, баш һәм иярчен җөмлә арасына куелырга тиешле тыныш билгеләрен дөрес кую;

10.Укучыларның сөйләм һәм язу культурасын үстерү, мөстәкыйль эшчәнлеген активлаштыру.

Белем-күнекмәләрне үзләштерү өчен, сыйныфта укучы 4 баланың 4 сендә дә әзерлек һәм фәнгә карата кызыксыну бар; уку сыйфаты уртачадан югары. 8 нче сыйныфны 4 укучыда "4" ле билгеләренә тәмамлады, өлгереш 100%, сыйфат 100 % тәшкил итте. Укучыларның грамоталылыгын һәм игътибарлылыгын үстерү буенча өстәмә эшләү таләп ителә. ДЙА әзерләнү барышында төрле төр тест биремнәре белән эшләү буенча да күнекмәләрне камилләштерергә кирәк.

**9 нчы сыйныфта бирелә торган һәм уку елы дәвамында укучылар үзләштерергә тиешле осталык һәм күнекмәләр:**

1.Әдәби әсәрнең жанрын тану һәм шуның стилен дәвам итеп, төрле төрдәге язма эшләр башкару (әдәбияттан алган мәгълүматлар күз алдында тотыла), әсәрнең төп идеясен аңлау, тексттагы проблемаларны формалаштыру, текстта күтәрелгән проблемаларны үз дәлилләрен китереп аңлата белү;

2.Изложение һәм сочинениеләрне, сөйләм төрләренә туры китерп, төрле жанрда язу.Язмаларны сыйфатлама, модальлек, эмоциональлек элементларын, стиль үзенчәлекләрен кулланып тулыландару һәм шомарту;

3.Әсәр яки аның бер өлеше нигезендә конспект төзү, тезислар әзерләү, кемгә дә булса характеристика язу;

4.Эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка,акт, гариза һәм беркетмәләрне мөстәкыйль рәвештә яза алу.

5. Җыелыш яки берәр утырышның беркетмәсен яза белү;

6. Мәктәп программасы таләп иткән күләмдә җөмлә составындагы сүзләргә фонетик, морфологик, грамматик анализ ясау, кушма җөмләләрне бер төрдән икенче төргә үзгәртә белү; кушма җөмләнең схемасын, төрен, иярчен җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше ягыннан төрен,иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитак һәм синтетик чараларны, баш һәм иярчен җөмлә арасына куелырга тиешле тыныш билгеләрен дөрес кую;

7. Укучыларның сөйләм һәм язу культурасын үстерү, мөстәкыйль эшчәнлеген активлаштыру.

5 – 9 нчы сыйныфларда татар теленең төп эчтәлеге өйрәнелә, укучыларга татар теленнән системалы, фәнни яктан ныклы белем бирелә, уку эшчәнлегенең төп төрләре формалаша һәм үстерелә. Татар теле фәне уку-укыту планында һәм белем бирүнең икенче баскычында белем бирү программасының төп нигезендәге фәннәрнең берсен тәшкил итә. 9 нчы сыйныф икенче баскычта белем бирүнең соңгы елы буларак, күбрәк кабатлау һәм системалаштыру дәресләренә, фәнни материал бирүгә корылган.

Татар теленнән эш программасы 9 нчы сыйныфта гамәлдәге базис план буенча атнага 2 сәгать исәбеннән төзелде. Татар мәктәбенең **9 нчы сыйныфында** татар теле дәресләре атнага 2 дәрес исәбеннән барлыгы **68 сәгатькә** каралган. Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

9 нчы сыйныфта татар теле дәресләре М.З.Зәкиев, С.М.Ибраһимовлар төзегән “Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныфы өчен татар теле дәреслеге” (Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2008 нче ел) буенча укытыла.

Өстәмә әдәбият буларак Н.В.Максимов төзегән “8 - 11 нче сыйныфлар өчен дидактик материаллар” (Казан,”Мәгариф” нәшрияты, 2004 нче ел) кулланыла

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр, тикшерү төрләре һәм бәяләү материаллары**

Гомуми төп белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфында ана теле предметын өйрәтү тел берәмлекләрен таный, аңлый һәм анализлый белү күнекмәләре белән бергә, сөйләм культурасын үстерүне, төрле типтагы һәм жанрдагы мәгълүматны үзләштерүне, аларны, сөйләм ситуациясенә һәм төренә карап, дөрес, төгәл итеп башкаларга җиткерә алуны, татар теленең әдәби һәм сөйләм әдәбе нормаларын күз алдында тота.

**Шәхси нәтиҗәләр**:

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңлау;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре тәрбияләү, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш уяту;
- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белү;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белү;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алышу.

**Предметны үзләштерү барышында ирешкән нәтиҗәләр:**

- сөйләмиятнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерү: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белү; аерым бер темага караган материалны туплый, анализлый, эшкәртә һәм үзгәртә белү;
- татар теленең төп функцияләрен, татар теленең башка төрки телләр арасында тоткан урынын, телнең мәдәният, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешен аңлау;
- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен булдыру, тел катламнарының, ярусларының үзара бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен аңлау;
- тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү, аның тармаклары турында мәгълүмат булдыру; тел һәм сөйләм, сөйләм төрләре, аралашу ситуацияләре; сөйләм теле, функциональ стильләр, матур әдәбият теле; текст һәм аның төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның аермалы билгеләрен, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белү;
- телнең төп стилистик чараларын, телнең әдәби нормаларын, сөйләм әдәбе нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү;

- тел һәм сөйләм берәмлекләрен аера һәм анализлый белү; тел һәм стилистик чараларның кулланылышына бәйле рәвештә сөйләм төрләрен аера һәм чагыштыра белү;
- телнең сәнгати чараларын аеру, аларның эстетик функцияләрен белү.

**9 нчы сыйныфта татар телен укытуның  предметара нәтиҗәләре:**

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәгетәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдыруда ролен ачыклау; чор әдәбиятына хас тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен ачу;
- телне әдәбият белән бәйләп, укыган яки тыңлаган әсәрнең эчтәлеген, планын, конспектын, резюмесын логик эзлекле итеп язарга, сөйләргә өйрәтү;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;
- татар телен рус теле белән бәйләп, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле–ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; телләрнең үзара бәгланыш-мөнәсәбәтләрен, шул мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә уртак төшенчәләр һәм тел берәмлекләре барлыкка килүне аңлату;
- рус һәм чит телләр, әдәбиятлар белән бәйләп, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен өйрәтү, алган белемнәрне төрле тел күренешләрен аңлатуда куллану;
- телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, аның үсеше турында күзаллау формалаштыру, җәмгыять үсешенең телгә турыдан-туры мөнәсәбәте булуын җиткерү;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү;сөйләмне дөрес куллана, бәяли белергә, үз фикереңнең уңай һәм тискәре якларын аңларга, камилләштерергә  өйрәтү;
- әдәби әсәрләрнең теле белән эшләгәндә, татар теле – бәйләүче чараларга бик бай тел, шул чаралар системасын, алар белдергән мәгънәләрне нәтиҗәлерәк үзләштерү максатыннан, стиль мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, фикерне төгәл бирердәй сүзтезмә һәм җөмләләрне телебез хәзинәсеннән сайлап ала белү.

**Түбәндә, максатына карап дәресләрдә кулланыла торган педагогик технологияләр:**

1. Шәхескә юнәлдерелгән
2. Тикшерү-проект
3. Эзләнү
4. Уку мәсьәләсен кую
5. ИКТ
6. Модульле-блоклы

**Программа нигезендә дәресләрнең эчтәлеге.**

“Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 5-9 нчы сыйныфлар өчен ана телен укыту программасы” укучылар үзләштерергә тиешле мәсьәләләр һәм темаларны гомумән күрсәтү белән чикләнә. Аларның **эчтәлеге** дәреслекләрдә ачыла. Тел дәресләрен әдәбият дәресләре белән тыгыз алып бару күздә тотыла. Бу укучылар сүзнең мәгънәсен, кулланыш үзенчәлеген, “тәмен” дөрес тоярга өйрәнсен өчен эшләнә. Өй эшләре күләме дәрестә башкарылганның өчтән бер өлешеннән артмаслык итеп билгеләнә. Яңа материалны аңлатуда әңгәмә алымы өстенлек ала. Дәресләрдә кыска гына диктант, изложение яки сочинениеләр яздыру да исәпкә алына. Болардан тыш дәресләрдә тулы күләмле язма эшләр дә үткәрелә. Бер үк вакытта алар балаларның белемнәрен тикшерү һәм бәяләү эшләре дә булып торалар.

Программа нигезендә үтелергә тиешле төп темаларга дәресләр бүленеше түбәндәгечә:

**Сөйләм.**

Тел һәм сөйләм. Сөйләмиятнең төрләре (сөйләү, тыңлау, язу, уку). Сөйләмнең төрләре (сөйләмә, язма, диалогик сөйләм, монологик сөйләм).Сөйләм төрләре һәм аларның үзенчәлекләре: язма сөйләм, фикерне, хәбәрне, укылган текст эчтәлеген орфография кагыйдәләренә нигезләнеп, грамматик дөрес язу. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен гамәли үзләштерү, аерым темалар буенча әңгәмә кору.

Кулланылышы ягыннан сөйләм төрләре, аларның үзенчәлекләре: көнкүреш аралашу теле, фәнни аралашу теле, иҗтимагый-сәяси аралашу теле, рәсми аралашу теле.

Сөйләм ситуациясе, аның төп компонентлары: адресат һәм адресант, сөйләм шартлары, шәхси аралашу, рәсми аралашу, алдан әзерләнгән сөйләм, әзерлексез сөйләм үзенчәлекләре. Сөйләм шартларына бәйле тел берәмлекләренең кулланылышы. Сөйләм нормалары: фонетик, лексик, морфологик һәм синтаксик нормалар.

**Сөйләм эшчәнлеге буларак текст.** Сөйләмә һәм язма текстлар.Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Текстның темасы, төп мәгънәсе. Текстның вграк кисәкләргә бүленеше. Текстның микротемасы. Сөйләмнең мәгънәви төрләре: тасвирлау, бәян итү, фикер йөртү. Текст структурасы. Текстның композицион, жанр төрлелеге. Текстка анализ ясау: темасын ачыклау, төп фикерне билгеләү, стилен билгеләү.

**Телнең кулланылыш ягыннан төрләре**: көнкүреш сөйләм теле, матур әдәбият теле, функциональ стильләр: фәнни стиль, публицистик стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хәзерге электрон чаралар теле. Фәнни стиль төрләре: реферат, чыгыш, доклад, мәкалә, бәяләмә. Публицистик стиль төрләре: чыгыш, интервью, очерк, мәкалә. Рәсми эш кәгазьләре стиле төрләре: ышанычнамә, гариза, резюме, портфолио. Сөйләм теле төрләре: хикәя, әңгәмә, бәхәс.

**Тел системасы**

**Татар теле турында гомуми мәгълүмат.**

Телнең аралашу чарасы булуы. Телнең төп функцияләре. Туган телнең һәрбер халык тормышында һәм кешене шәхес итеп формалаштырудагы роле.

Кардәш һәм кардәш булмаган телләр. Татарлар яши торган төбәкләр.

Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны.

**Фонетика һәм орфоэпия**.

Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Сөйләм органнары, аларның авазларны ясауда катнашуы. Аваз. Фонема. Татар телендә сузык авазлар, аларның саны. Сузык авазларны төркемләү. Татар телендә сузык авазлар өлкәсендәге үзгәрешләр. Сингармонизм законы, аның төрләре. Татар телендә сузыклар кыскару күренеше. Дифтонглар турында төшенчә. Татар телендә тартык авазлар, аларның саны. Тартык авазларны

төркемләү. Тартык авазлар өлкәсендәге үзгәрешләр. Тартык авазларның охшашлануы. Аның төрләре. Татар һәм рус телләрендә сузык авазлар һәм тартык авазлар.

Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынма сүзләрдә басым сакланмау очраклары. Интонация белән эшләү.

Әдәби тел нормалары. Орфоэпик нормалар турында төшенчә. Орфоэпик сүзлек.

Фонетик анализ ясау.

**Графика**

Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар алфавиты.

Орфография. Сузык аваз хәрефләренең дөрес язылышы. Тартык аваз хәрефләренең дөрес язылышы. Икешәр аваз кушылмасын белдергән хәрефләрнең дөрес язылышы. ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы.

Орфографик сүзлек. Телнең орфографик нормалары.

**Морфемика (сүз төзелеше) һәм ясалышы**

Сүз төзелеше һәм ясалышы турында гомуми мәгълүмат. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр һәм кушымча. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясалу. Аларның сүз төркемнәрен ясаудагы роле.

Кушымчалар, аларның төрләре: сүз ясагыч кушымчалар, мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. Тамыр һәм ясалма нигез.

Татар телендә сүз ясалыш ысуллары. Татар телендә тамыр сүзләр. Ясалма сүзләр. Кушма сүзләр, аларның төрләре: саф кушма, тезмә һәм парлы сүзләр.

Татар һәм рус телләрендәге сүз төзелешенең төп аермалы яклары.Этимология турында төшенчә.

Сүзләрне сүз ясалышы һәм төзелеше ягыннан анализлау.

**Лексикология һәм фразеология.**

Сүз – телнең төп берәмлеге. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. Туры һәм күчерелмә мәгънәләр. Антонимнар. Синонимнар. Паронимнар. Омонимнар һәм аларның төрләре.

Төрки-татар сүзләре һәм алынма сүзләр.

Татар теленең сүзлек составы: искергән сүзләр, тарихи сүзләр һәм неологизмнар, аларның төрләре. Диалекталь лексика, һөнәрчелек лексикасы, терминологик лексика, жаргон сүзләр.

Фразеологик әйтелмәләр, аларны мәгънәсе. Фразеологизмнарның сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре.

Татар теленең төп сүзлекләре, аларны куллана белү.

Татар теленең төп лексик нормалары. Лексик анализ ясау.

**Морфология**

Сүз төркемнәренең лексик-грамматик төрләре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Мөстәкыйль сүз төркемнәре, ярдәмлек сүз төркемнәре, модаль сүз төркемнәре. Аларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.

Сүз төркемнәренең ясалышы, семантикасы, кулланылыш үзенчәлекләре.

Телнең төп морфологик нормалары.

Морфологик анализ ясау.

**Синтаксис**

Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат. Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Тезүле һәм ияртүле бәйләнешләр.

Җөмлә турында төшенчә. Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләр. Җөмләдә сүз тәртибе.

Гади җөмлә төрләре. Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә. Тулы һәм ким җөмлә. Сөйләмдә бер составлы җөмләләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.

Раслау һәм инкарь җөмлә турында гомуми төшенчә.

Туры һәм кыек сөйләм. Диалог, аның язылышы, тыныш билгеләре.

Кушма җөмлә турында төшенчә. Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.

Иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләнең төзелеше. Синтетик иярченле кушма җөмлә, аның бәйләүче чаралары, тыныш билгеләре. Аналитик иярченле кушма җөмлә, аның бәйләүче чаралары, тыныш билгеләре.

Иярчен җөмлә һәм аның төрләре. Катлаулы кушма җөмләләр.

Текст синтаксисы турында гомуми төшенчә.

Телнең төп синтаксик нормалары.

Синтаксик анализ ясау.

**Сөйләм культурасы**

Язма тел һәм сөйләмә тел төшенчәләре. Сөйләмдә синонимнарны, антонимнар һ.б. тел чараларын дөрес куллану. Әдәби телне, сөйләм культурасын үстерүдә һәм стильне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле.

Сөйләм культурасы төшенчәсе. Әдәби сөйләмгә куелган таләпләр турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмдә лексик чараларның (синонимнар, антонимнар, калькалар, фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр) кулланылыш мөмкинлекләре.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Ия белән хәбәр арасына сызык кую очраклары. Хәл, аныклагыч, эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

Диалог, аның язылышы, тыныш билгеләре. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре.

Кушма җөмлә янында тыныш билгеләре.

**Тел һәм мәдәният**

Татар сөйләм әдәбе. Аралашуның төренә бәйле сөйләм әдәбен куллану.

Сүздә, текстта милли-мәдәни мәгънәгә ия берәмлекләрне таба һәм аңлатмалы, этимологик, фразеологик һ.б. сүзлекләр ярдәмендә мәгънәләрен аңлату.

**<u>Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр</u>**

**Фонетика буенча**:

- сүзләргә фонетик анализ ясау;
- орфоэпик һәм орфографик сүзлекләрдән файдалану;

**Лексикология буенча:**

- Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану. Сүз төркемнәрен куллануда стилистик төрлелек.
- Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы буенча:**

- сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш сүзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
- Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.
- Кушымчаларны төркемли һәм төркемнәргә аера белү. Шулай ук кушымчаларны “укый” белү

**Морфология буенча:**

- мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәренә хас билгеләрне белү; аларны аеру, төркемләү, аларның төрләнеш үзенчәлекләрен белү һәм төрләндерә белү;
- өйрәнелгән сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясау.
- өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Суз төркемнәренең төрле ысул белән ясалышын белү.
- Сүз төркемнәрен дөрес язу һәм уку;

**Синтаксис буенча:**

- Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
- Гади һәм кушма җөмләләрне аера белү.
- Җөмләнең әйтү максаты буенча төрен билгели белү.
- Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табып, аларның кайсы сүз төркемнәре белән белдерелүен күрсәтү.
- **Эш кәгазьләре буенча:**
- төрле эш кәгазьләрен (мәкалә, акт, расписка һ..б.) яза белү

**Сөйләм эшчәнлеге буенча:**

- Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
- Укыган яки тыңлаган текстның эчтәлеген сөйләү, планын төзү.
- Бирелгән план буенча сочинение (хикәя) язу.
- Татарчадан русчага яки русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре эшләү.

**Гомуми төп белем бирү мәктәбенең 5-9 нчы сыйныфларында укучыларның ана теленнән белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары:**

**1. Уку күнекмәсен тикшерү һәм бәяләү:**

5 нче сыйныфта – 100 - 110 сүз,
6 нчы сыйныфта – 110 – 120 сүз
7 нче сыйныфта – 130 – 140 сүз
8, 9 нчы сыйныфларда – 140 – 150 сүз

3. Язма эшләрнең күләме һәм аны бәяләү:

| Сыйныфлар | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
|---|---|---|---|
| 5 | 4 | 5 | 4 |
| 6 | 4 | 6 | 5 |
| 7 | 4 | 6 | 6 |
| 8 | 4 | 4 | 6 |
| 9 | 4 | 4 | 7 |

Сүзлек диктанты –35-40 сүз
**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант- ел башында 110 сүз, ел ахырында 120 сүз

**3. Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме
ел башында 450-475 сүз (220 - 240 – язма күләме)
ел ахырында 475 – 500 сүз (240-250 язма күләме)

**4. Изложениене бәяләү**

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)

2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела. Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби- иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**5. Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге саклanса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**6. Изложение яздыру һәм язу методикасы**

Теле һәм эчтәлеге ягыннан укучыга аңлаешлы текстны укутучы сәнгатьле итеп ике кат(сүзләрдәге авазларны ачык әйтеп,синтамга һәм җөмлә чикләрен тиешле интонация белән дөрес билгеләп, җөмләләрдәге тиңдәш һәм аерымланган иярчен кисәкләрнең чикләрен билгели алырлык итеп,кереш һәм эндәш сүзләрне,туры сөйләм формаларын сиземләрлек итеп,фактик мәгълүматларга логик басым ясап) укып чыга.

Текстта укучыга таныш булмаган сүзләр ,фразеологик әйтелмәләр тактага язып яки телдән аңлатыла.

Укытучы текстны укыганда,укучы нәрсәләр эшли ала?

Хәтерендә калдырыга авыр ,ләкин эчтәлекне бирү өчен мөһим булган кайбер нәрсәләрне,мәсәлән,ялгызлык исемнәрне,даталарны, саннарны,аерым сүзтезмәләрне,туры сөйләмне һ.б. дәфтәр битенә теркәп барырга мөмкин.

Текстта фикер эзлеклеге югалмасын өчен, үзе кирәк дип санаган фикерләрне язып бара ала.Ләкин укучы шуны истә тотарга тиеш: язып,теркәп барулар укыла торган текстны тулысы белән хәтерендә калдырыга комаучаламасын.

Укучы язмасында текстның эчтәлеген генә “сөйләп чыгырга” тиеш түгел,ә бәлки текстның (фәнни,публицистик,әдәби) стиль үзенчәлекләрен саклаган хәлдә,эчтәлекне мөмкин кадәр текстка якын бирергә тиеш.Ягъни укучы, текстның эчтәлеген, эзлеклелеген үзгәртмичә, күләмен өлешчә (70% ка кадәр киметеп) үзгәртеп, сүз һәм җөмләләрне өлешчә файдаланып, аны әдәби язма телдә бирергә бурычлы.Шуңа күрә укучы, укытучы текстны бер кат укыгач,эчтәлеге хәтерендә яхшырак калсын өчен,текстны, эзлекле итеп, эчтән генә сөйләп чыксын.Шуннан соң укучы изложениенең гади катлаулы планын төзи.Аннары, планга нигезләнеп, эчтәлекне тагын бер кат эчтән генә “сөйләп” чыга.Укытучы текстны икенче-соңгы кат укыганда, укучы эчтәлекне тулыландырырга, камилләштерергә,кирәк булган сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне “алып калырга” тырышы.Моның өчен абзац яисә җөмләләрдәге төп фикерне ачарга ярдәм итүче сүзтезмәләр һәм сүзләрне төгәл бирергә омтылырга кирәк.Болай эшләгәндә, ягъни текстның “өлгесе” алынганда, эчтәлекне язмада тулы һәм аңлаешлы, эзлекле һәм бәйләнешле итеп бирү тагын да җиңеләя.

Текст соңгы кабат укылгач, укучы, төзелгән планын тагын бер кат карап чыгып, кирәк дип тапса, өстәмәләр кеттә.Аннары, шул планга нигезләнеп,язмасының эчтәлеген һәм төзелешен тулысынча аныклап, ашыкмыйча гына яза башлый.

**7. Язманы камилләштерү**

Изложение язганда, укучы, текстның эчтәлеген язмасында эзлекле һәм дөрес бирү белән бергә, тиешле урында тыныш билгеләрен куярга, сүзләрнең ясалыш, язылыш, төрләнеш, һәм бер-берсе белән ялгану үзенчәлекләрен истән чыгармаска тиеш.Ягъни язмада сүзне төрле формаларын кирәкле урында тиешле мәгънәсендә куллана,контекст таләп иткән синонимны, сурәт чарасын файдалана белергә, гади җөмләләрнең бәйләнешен дөрес оештырырга, җөмләләр эчендә һәм ахырында тыныш билгеләрен дөрес куя белергә кирәк. Боларның барысы да текстның үзенә генә хас стилен саклап язарга ярдәм итә.

Тиешле урында кулланылган һәр сүз, сүзтезмә, җөмлә, тыныш билгесе текстның эчтәлеген һәм стилен язмада төгәл бирүдә зур роль уйный. Шуңа күрә, һәр сүзне урынлы куллану кирәк булган кебек, һәр тыныш билгесен тиешле урынына куярга кирәк. Аларны куймый калдырырга да, берсе урынына икенчесен куярга да ярамый.Шуны да истән чыгармагыз: текстта куелган һәр тыныш билгесенең язмада кабатлануы мәҗбүри түгел, ягъни укучы текстта бирелгән кайбер кушма җөмләләрне гади җөмләләр белән бирә; тиңдәш кисәкләр һәм кушма җөмлә составындагы гади җөмләләр арасындагы өтер, нокталы өтер урынына теркәгечләр, кисәкчәләр куллана яки, киресенчә, теркәгеч һәм кисәкчәләрне төшереп калдырып, алар урынына өтер, нокталы, өтер кебек тыныш билгеләрен файдалана ала.

Сыйныфның әзерлеген исәпкә алып, укытучы, алда үтелгән теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, грамматик бирем дә бирә ала.

**8. Сочинение яздыру һәм язу методикасы**

Изложениедә, үз карашыңны белдерми генә, тыңланган кечерәк күләмле текстның эчтәлеге язылa.Сочинение язганда исә, өйрәнелгән зур күләмле әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга;шуларга бәйләп, язучы яшәгән, әсәрнең нигезенә алынган чорга, ул вакыттагы тарихи һәм иҗтимагый шартларга; шул чорга хас әхлакый нормаларга; әсәрдә бирелгән геройларга һ.б. карата мөнәсәбәтеңне белдереп,үзеңнең әдәби язма текстыңны "тудырасың".

Сочинение укучыларның тормыш күзәтүләреннән алган тәэсирләрен язмада грамоталы һәм эзлекле бирә белү, әдәби әсәрнең эчтәлеген үз сүзләре белән образлы телдә бәйләнешле итеп яза алу мөмкинлеген тикшерү максатыннан яздырыла.Шулай ук укучыларның тел һәм әдәбият дәресләрендә алган белемнәрен ныгыту, тирәнәйтүне күздә тотып та үткәрелә.

Әдәби сочинениеләр кайсы да булса әсәр (яки өзек) үтелеп беткәч яздырыла.Сочинение темасын укытучы бирә, язылу алымын (хикәяләү, хат, очерк, истәлек, рецензия һ.б.)укучылар үзләре сайлый.

Әдәби сочиненеләр 5-8 нче сыйныфларда-өйрәтү һәм контроль сочинение буларак үткәрелә. Аларда әсәрнең төп героена - өлешчә яки тулы, образларга чагыштырма характеристика бирелә, әсәрнең эчтәлеген ачу, сәнгатьчә эшләнешен бәяләү кебек эшләр үткәрелә.

Әдәби-иҗади сочинениеләр мөстәкыйль укылган яки дәресләрдә үткән әсәргә, андагы образ һәм вакыйгаларга карата укучы фикерен белү масатыннан яздырыла.Андый сочинениеләрне өйдә яздырганда, укучы, тәнкыйди материалларны тулырак файдаланып, үз мөнәсәбәтен ачыграк бирә ала.

Өйрәтү характерындагы сочинениеләрне язганда, укучы текст, әсәр турындагы тәнкыйть материалларыннан, сүзлекләрдән файдалана ала.

Контроль сочинениеләрне язганда, өзекне (цитатаны) бирүдә хилафлык булмасын өчен, укучыга әсәр текстыннан файдаланырга рөхсәт ителә.

Сочинениеләр картиналар нигезендә дә яздырылырга мөмкин. Укучылар картина темасын үзләренчә ачсалар да, язу алымын (жанрын) укытучы билгели. Бу төр сочинениене яздырыр алдынна төрле әсәрләрдән эятәлекне тулыландырыга ярдәм итәрлек өзекләр укылса, нәтиҗә тагын да яхшырак була.

Ирекле сочинениеләрдә тәкъдим ителгән теманы укучы үзенчә ача, вакыйга һәм геройларга, геройларның үзара мөнәсәбәтенә бәя бирә, үз фикерләрен исбатлау өчен, башка чыганаклардан һәм хыялый мөмкинлекләреннән файдалана. Бу төр сочинениеләр өчен күпмедер уртаклыгы булган берничә тема яки гомуми бер тема сайлана.

Сочинение язарга әзерлек барышында татар әдәбиятынннан программаларга карарга кирәк, чөнки темаларның барысы да мәктәп программасына нигезләнеп алына. Шуның белән бергә, дәрестән тыш укылганнарны тикшерү өчен, 1-2 ирекле тема да тәкъдим ителә.

Тема турында уйлый башлагач та, фикерләр туа.Аларны кыскача терки барырга. өйрәтелә. Шулай яза барганда, фикер тупланмасы барлыкка килер. Аннары, шул фикерләргә таянып, язманың планы төзелә.

Ни өчен план язарга кирәк соң? Сочинение ул- кечкенә күләмле фәнни эш, шуңа күрә,аны логик яктан төзек,эзлекле фактларга таянып язу өчен, план төзүнең әһәмияте бик зур.

Сочинениенең кереш һәм йомгаклау өлеше гомуми күләмнең өчтән берен алып торырга тиеш, ягъни сочинениегез уртача 3-4 бит булса, шуның 0,5 - 1 бите кереш һәм йомгаклау өлешенә бирелә.

Эзлекле һәм тулы язар өчен, план төзи белергә кирәк. Дөрес төзелгән план ул- язманың нигезе.План язмагызның эзлекле бирелгән кыскача эчтәлеген чагылдырырга тиеш.Тикшерүче, планга карап, сезнең сочинениегезнең төп темасын, әйтергә теләгән фикерегезне фактларга таянып дәлиллли һәм нәтиҗә ясый белүегезне күрә алырлык булсын.

План төзегәндә,сочинениенең төп өлешләре билгеләнә һәм бу өлешләр тагын да кечерәк өлешләргә бүленә.

План төзелеп беткәч, аның өлешләре арсындагы бәйләнешне җентекләп тикшереп чыгарга. Кирәк урыннарга кертеләсе өзекләрне(цитаталарны) билгеләргә. Шуннан соң, планыгызга нигезләнеп, язасы фикеркезне эчтән генә сөйләп чыгыгыз һәм ашыкмыйча гына яза башлагыз.

Язма эштән соң беренче юлга, кызыл юл турысыннан башлап, ялгышларның саны күрсәтелә: башта-орфографик,анна соң пунктуацион һәм стилистик хаталар саны языла.Аларны ике нокта аша күрсәтергә була:1:3:2.Бу язылыш 1 орфографик, 3 пунктуацион, 2 стиль хатасы барлыкны аңлата.

**9. Изложение һәм сочинениеләрдә еш очрый торган хаталар:**

--сүз ясалышында хата җибәрү;

--сүзтезмә яки җөмләләрн дөрес төземәү;

--сүз формаларын дөрес кулланмау: бер килеш кушымчасы урынынаикенчесен язу, тартым һәм зат-сан кушымчаларын бутау, җөмлә кисәкләрен бәйләүдәге төгәлсезлекләр;

--фигыль заманнарын бутау;

--тиңдәш түгел аергычлар арасына өтер кую;

--чикләрен дөрес билгеләмәү аркасында, тыныш билгеләрен үз урынына куймау(аерымланган иярчен кисәкләргә һәм эндәш сзләргә хас);

--фразаара бәйләнеш чараларын дөрес файдаланмау(бу төр кимчелекләрне сөйләм тйгәлсезлегенә дә кертергә ярый);

--туры сөйләм өлешләрен бутау h.б.

Логик хаталар: орфографик һәм грамматик кагыйдәләрне бозу нәтиҗәсендә мәгънә төгәлсезлегенә китерә торган кимчелекләр.

Фактик хаталар:әсәр исемен,вакыйгаларны,чорны (гасыр,ел,ай,көн һ.б.);персонажларның (герой,канашучы яки аның турында нинди дә булса фикер әйтүче кешенең) исем һәм фамилияләрен,алынган цитаталарның чыганагын бутау;техник төгәлсезлекләр.

Барлык төр хаталар исәпкә алынып, изложение белән сочинениеләргә ике билге куела: беренчесе-эшнең эчтәлеге белән теленә,икенчнсе грамоталылыгына.Укучы дәфтәрләрендә алар 5/4, 4/5, 3/4 һ.б.(санаучыда- беренче,ваклаучыда- икенче бәяләр рәвешендә куела).

Башлангыч сыйныф укучыларының-бөтен төр язма эшләре, 5-8 нче сыйныф укучыларының диктантлары, язма эш башкарылган көнне санамыйча, чираттагы татр теле дәресенә кадәр тикшерелсә, 5-8 нче сыйныфларда изложение һәм сочинениеләре өчен 5-7 , өй сочинениеләрен тикшерүгә 10-12 көн вакыт бирелә. Язма эшләр укучыларга кайтарылганнан соң, алар хаталарын төзәтепяза.Контроль язма эшләр кире кайтарылмый.Уңай бәяләнмәгән язма эшләр укучы тарафыннан яңадан эшләнеш,диктантлар күчертеп яздырыла;изложение һәм сочинениеләр, укытучы күрсәтмәләре нигезендә,кабат башкарыла.Андый эшләр 1 баллга түбән бәяләнә.

**Агымдагы, арадаш һәм йомгаклау аттестациясендә укучыларның белемнәрен бәяләү материаллары:**

*Укучыларның белемнәрен бәяләү максатыннан, программа нигезендә 9 нчы сыйныфта контроль диктант, контроль сочинение, контроль изложение яздыру каралган. Дәүләт йомгаклау аттестациясендә укучыларның белемнәре КҮМ буенча үткәрелә. КҮМ үз эченә теоретик сораулардан төзелгән тестны үз эченә алган А өлешеннән, өлешчә практик биремнәрне үз эченә алган В өлешеннән, изложение язу һәм шул изложениедәге төп идеядән чыгып үз фикереңне белдерү максатыннан сочинение язуны үз эченә алган С өлешеннән тора. ДЙА нә әзерлек максатыннан, уку елының 1 нче яртысында үткәрелә торган агымдагы аттестациядә һәм уку елы ахырындагы арадаш аттестациядә КҮМ буенча комплекслы контроль эш үткәрү каралды.*

## Дәресләрне укытуны тематик планлаштыру

**Фән** *Татар теле* **Сыйныф** *9* **Укытучы** *Әхмәтшина Лариса Михаил кызы*

**Дәресләр саны**

| **Сыйныф** | **Барлыгы** | **Атнага** |
|---|---|---|
| 9 | 68 | 2 |

**Планлаштырылган контроль эшләр**

| **Сыйныф** | **Барлыгы** | **Административ к/э** | **Мөст. эш (тест)** | **СҮ** |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Диктант-3<br>Изложение-4<br>Сочинение-2 | 2 | 1 | 8 |

**Программа**

"Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа" (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: Г.Р.Галиуллина, М.М.Шәкүрова, Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2013 ел.

**Дәреслек**

| **Сыйныф** | **Автор** | **Дәреслек** | **Нәшрият** | **Басма елы** |
|---|---|---|---|---|
| 9 | М.З.Зәкиев<br>С.М.Ибраһимов | "Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен татар теле дәреслеге" | Казан, "Мәгариф" | 2008 |

**Өстәмә әдәбият**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | 1. М.З.Зәкиев.<br>2. Н.В. Максимов | "Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дидактик материал | Казан, "Мәгариф" | 1998<br><br>2003 |

| № | Дәрес темасы<br>Дәрес эчтәлеге элементлары | Дәрес тибы | Материалны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәсе | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль формасы | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | план | факт |
| **1 нче чирек** | | | | | | | |
| | **Тел турында әңгәмә -1** | | | | | | |
| 1 | Әңгәмә “Туган телем – газиз телем”. Тел һәм аны өйрәнүче фәннәр | Катнаш | Тел һәм аны өйрәнүче фәннәр турында белешмә | Тел һәм аны өйрәнүче, аңа бәйле булган фәннәрне белү | әңгәмәдә катнашу, дәреслек белән эшләү, сорауларга җавап | 01.09 | |
| | **Фонетика, орфоэпия, орфография - 4** | | | | | | |
| 2 | Орфография, орфоэпия. Сөйләм авазлары, аларның кулланылышы | Катнаш | Аваз һәм фонема. Сөйләм авазлары, аларның кулланылышы | Әңгәмә, күчереп язу, телдән җаваплар, күнегүләр эшләү. | Телдән җаваплар, мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 04.09 | |
| 3 | Авазларның чиратлашуы, авазлар чиратлашканда, мәгънәнең үзгәрүе. | Катнаш | Авазларның охшашлануы (уңай һәм кире ассимиляция), чиратлашуы, йотылуы. Авазлар үзгәрү – чиратлашуның мәгънә үзгәрешенә китерүе. | Телдән җаваплар, мөстәкыйль күнегүләр эшләү, сүзләргә фонетик анализ | Телдән һәм язма җавапларны бәяләү | 08.09 | |
| 4 | Дөрес әйтү һәм язу. Сүзнең әйтелеше һәм язылышы. Транскрипция | Катнаш | Сузык һәм тартык авазларны дөрес итеп әйтү һәм язуда күрсәтү | Әңгәмә, күчереп язу, телдән җаваплар, күнегүләр эшләү. Җөмләләрне транскрипциядә күрсәтү. | Текстларның транскрипция-сен язу | 11.09 | |
| 5 | Дөрес әйтү һәм язу, сүз ярдәмендә белдерелгән мәгънә. Татар теленең төп принциплары. | Катнаш | Татар теленең төп принциплары | Телдән җаваплар, мөстәкыйль күнегүләр эшләү, сүзләргә фонетик анализ | Сүзләргә фонетик анализ | 15.09 | |
| 6 | **СҮ. Авазларны язуда дөрес бирүгә аңлатмалы диктант язу.** | Белемнәрне тикшерү | Диагностик диктант: хаталарын бергәләп анализлау, укучыларның уку елы башына белем | Язма сөйләмдә хәзерге татар әдәби теленең орфографик, лексик, грамматик нормаларын | Диктант язу һәм грамматик бирем үтәү | 18.09 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | дәрәҗәләрен билгеләү. | үтәү | | | |
| | **Лексика, лексикология - 4** | | | | | | |
| 7 | Лексика, татар әдәби теленең сүзлек составы. Сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәсе | Катнаш | Телнең сүзлек составының лексика дип йөртелүе. Лексика турындагы фәннең лексикология дип аталуы. Сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләре. Синоним, омоним, антонимнар. Фразеология фәне. Фразеологизмнар. | Укытучы сөйләме. Сорауларга җавап бирү. Синоним, омоним, антонимнарны табу, билгеләмәләрен белү, парларын табу | Иҗади биремнәр | 22.09 | |
| 8 | Лексик берәмлекләрне җыю. Лексикография. | Ныгыту | Сүзлекләр төзү турындагы фәннең лексикография дип аталуы. Аңлатмалы, телара сүзлекләр.. | Сүзлекләр белән эшләү күнекмәләре | Күнегүләр эшләү, сүзлекләр белән эш | 25.09 | |
| 9 | Сүзлекләр, аларның төрләре. Сүзлекләр белән эшләү күнекмәләре | Ныгыту | Аңлатмалы, телара сүзлекләр. Нинди дә булса бер тел сүзләренең мәгънәсен шул ук телдә аңлатып бирә тора сүзлекләрнең аңлатмалы сүзлекләр дип аталуы. Бер телдәге сүзләрнең мәгънәсен икенче телдә аңлатып бирә торган сүзлекләрнең телара сүзлекләр дип аталуы. | Сүзлекләр белән эшләү күнекмәләре | Күнегүләр эшләү, сүзлекләр белән эш | 29.09 | |
| 10 | Лексика буенча күнегүләр эшләү. Фразеологизмнар. | Ныгыту | Лексика буенча белемнәрне практик күнегүләрдә куллану.. Фразеологизмнарны тексттан танып белү, аңлатмаларын табу . | Дәреслек белән эш, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эшләү | Фразеологизмнарга аңлатма, телдән һәм язмача күнегүләр, сүзлекләр белән эш | 02.10 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | **СҮ. “Лексика” темасына изложение язарга әзерләнү.** | Сөйләм үстерү | Текстның планын төзү, эчтәлегең сөйләү, изложение язу үз сөйләмеңнең, төзегән текстларныың дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү. | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, караламада язма сөйләм төзү; язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Текстка якын язма сөйләм төзү | 06.10 | |
| 12 | **СҮ. "Лексика" темасын өйрәнүгә сочинение элементлары белән к/изложение язу.** | Сөйләм үстерү | Телдән һәм язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү | План нигезендә изложение язу, төзегән текстның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Изложение | 09.10 | |
| | **Сүз ясалышы һәм төзелеше - 2** | | | | | | |
| 13 | Сүзләрнең ясалышы һәм язылышы: тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма сүзләр. | Ныгыту | Сүз ясалышы һәм сүз төзелеше мәсьәләләрен өйрәнә торган бүлекнең сүз ясалышы дип аталуын, татар теленең сүз ясалышы юлларын белү. Ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма сүзләрне дөрес яза белү. | Бирелгән сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен табу, төзелеше ягыннан тикшерү.<br>Сүз ясалышы ысулларының һәрберсенә мисаллар уйлап язу.<br>Тексттагы тамыр һәм ясалма сүзләрне аерып әйтү, ясалма сүзнең тамырын һәм кушымчасын билгеләү.<br>Сүзләрне яс. Һ.төз. ягыннан тикшерү. | Сүзләрне ясалышы ягыннан тикшерү, мөстәкыйль эш | 13.10 | |
| 14 | Сүз ясалышы һәм төзелеше | Ныгыту | Сүзләрне ясалышы һәм төзелеше ягыннан анализлый белү. | Бирелгән сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен табу, ясалыш төрен күрсәтү, төзелеше ягыннан тикшерү. | Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерү, схемада күрсзтү | 16.10 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | **СҮ. “Сүз ясалышы һәм төзелеше” темасына иҗади-грамматик диктант.** | Сөйләм үстерү | Язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Дәрестә алган белемнәрне кулланып, грамоталы һәм чиста язу күнекмәсен камилләштерү. | Диктант, грамматик бирем | 20.10 | |
| | **Морфология - 3** | | | | | | |
| 16 | Морфология, сүз төркемнәре: мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре, ярдәмлек сүз төркемнәре. | Ныгыту | Морфология, ярдәмлек һәм мөстәкыйль сүз төркемнәре, аларның мәгънәләре | Барлык сүзләрнең дә сүз төркемнәрен билгели белү, сораулар кую, җөмләдәге ролен билгеләү | Күнегүләр эшләү, сүз төркемнәрен билгеләү | 23.10 | |
| 17 | Кушымчалар, аларның җөмлә төзүдәге роле | Ныгыту | Төрләндергеч кушымчаларның морфологиягә каравын аңлау, ясагыч, төрләндергеч, модаль һәм бәйләгеч кушымчаларның функцияләрен белү. | Сүзләрдәге кушымчаларның функцияләрен аңлату. Сүзләргә тиешле кушымчаларны куеп язу. Кушымчаларның кайсы сүз төркеменә ялгануын әйтү. | Контроль күнегү | 27.10 | |
| 18 | “Морфология” темасына күнегүләр эшләү | Практик күнекмәләр | Барлык сүзләрнең дә сүз төркемнәрен билгели белү, сораулар кую, җөмләдәге ролен билгеләү | Сүзләрнең сүз төркемнәрен билгеләү, кагыйдәләрен белү | Тест , дидактик материаллардан күнегүләр | 30.10 | |
| | | | **2 нче чирек** | | | | |
| 19 | **СҮ. “Морфология” темасына практик эш (КҮМ буенча)** | Практик күнекмәләр | Алган белемнәрне практик биремнәрдә куллану | Биремнәргә мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алу. | Тест, сорауларга җаваплар, практик биремнәр | 10.11 | |
| | **Синтаксис һәм тыныш билгеләре - 7** | | | | | | |
| 20 | Синтаксис. Синтаксик берәмлекләр. Сүзләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләре:тезүле һәм ияртүле бәйләнеш, ияртүче һәм ияручe компонент; хәбәрлекле, ачыклаулы, | Катнаш | Тел гыйлеменең бер тармагы буларак,синтаксисның сөйләм төзелешен өйрәнүен белү. Ияртүле һәм тезүле бәйләнеш, ияртүче һәм ияручe компонент; | Дәреслек белән эшләү, схемалар төзү; телдән җаваплар, язмача һәм телдән күнегүләр | Телдән җаваплар, кагыйдәләрне белү, күнегүләр эшләү | 13.11 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аныклаулы мөнәсәбәтләр. | | хәбәрлекле, ачыклаулы, аныклаулы мөнәсәбәт турында мәгълүматлы булу. | | | | |
| 21 | Гади җөмлә төрләре. Гади җөмләдә тыныш билгеләре. | Ныгыту | Гади җөмләгә билгеләмә, гади җумләнең төрләрен белү, төрле тыныш билгеләрен кую очраклары | Дәреслек белән эшләү, схемалар төзү; телдән җаваплар, язмача һәм телдән күнегүләр | Телдән җаваплар, кагыйдәләрне белү, күнегүләр эшләү | 17.11 | |
| 22 | Ия белән хәбәр арасында сызык кую очраклары | Ныгыту | Ия белән хәбәр арасында сызык кую һәм исемне исем ачыклаган аныклагычлар арсында сызык кую очракларына игътибар итү. | Текст эчендә очраган тыныш билгеләрен куюның барлык очракларын да аңлата белү | Тыныш билгеләрен куюга телдән һәм язмача күнегүләр | 20.11 | |
| 23 | Аерымланган кисәкләр, аерымланган хәлләр һәм аныклагычлар янында тыныш билгеләре. | Ныгыту | Үзләре бәйләнгән җөмлә кисәгеннән ераклаштырылган һәм ярым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган хәлләрнең аерымлануы. Үзләре бәйләнгән җөмлә кисәгеннән ераклаштырылган һәм ярым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган хәлләрнең башка җөмлә кисәкләреннән өтер яки өтерләр белән аерып алынуы. Уртада килгәндә, аерымланган хәлләрнең ике яктан да өтер белән аерылуы, калган очракта өтернең бер яктан гына куелуы. | Җөмләнең аерымланган кисәкләре һәм аерымланган хәлләр, хәлләрнең аерымлану очраклары турында төшенчә булу. Аерымланган хәлләрне танып белү. | Күнегүләр эшләү Контроль күнегү | 24.11 | |
| 24 | Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.Тиңдәш кисәкләр арасында | Ныгыту | Тиңдәш кисәкләрнең тезүче теркәгечләр белән дә, теркәгечләр булмыйча, тик | Тыныш билгеләре куюга күнегүләр эшләү. | Карточкалар белән эш, иҗади биремнәр. | 27.11 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | теркәгечле һәм теркәгечсез бәйләнеш. | | санау интонациясе ярдәмендә дә үзара бәйләнә ала икәнлеген белдерү. Теркәгечләрдән башка гына бәйләнгән тиңдәш кисәкләр арасына өтер, нокталы өтер, сызык куелу очраклары. Тиңдәш кисәкләр янында һәм, яки теркәгечләре кабатланмаса, өтернең куелмавы. | | | | |
| 25 | **СҮ. “Гади җөмләдә тыныш билгеләре” темасына изложение язарга әзерләнү** | Сөйләм үстерү | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, изложение язу үз сөйләмеңнең, төзегән текстларныың дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, караламада язма сөйләм төзү; язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Текстка якын язма сөйләм төзү | 01.12 | |
| 26 | **СҮ. “Гади җөмләдә тыныш билгеләре” темасына сочинение элементлары белән изложение язу** | Сөйләм үстерү | Телдән һәм язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү | План нигезендә изложение язу, төзегән текстның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Изложение | 04.12 | |
| 27 | Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә аның төрләре; тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | Ныгыту | Кушма җөмләдә тыныш билгеләре куелышының җөмләләрнең бәйләнеш төренә (синтаксик төзелеш) һәм синтетик, аналитик төзелешкә бәйле булуын белү. Тезмә кушма җөмләдә өтер, сызык куелу очракларын белү, мисаллар ярдәмендә аңлату. | Җөмләләрне күчереп язу, бәйләүче чараларны һәм тыныш билгеләренең куелышын җөмлә төреннән чыгып аңлату. Схема төрләрен искә төшерү, төзү. | Текст белән эш, текст эчендә тезмә кушма җөмләләрне танып белү һәм аларга синтаксик анализ ясау. | 08.12 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмләдә тыныш билгеләре | Ныгыту | Иярченле кушма җөмләдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү. Синтетик иярченле кушма җөмләдә өтер, сызык куелу һәм тыныш билгеләренең куелмый торган очракларын аңлый һәм аңлату; Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куеп яза белү.. | Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне күчереп язу, бәйләүче чараларны һәм тыныш билгеләренең куелышын җөмлә төреннән чыгып аңлату. Баш җөмлә белән ичрчен җөмлә арасында тыныш билгеләре куелмау очрагын аңлату. Схемаларын төзү. | Текст белән эш, текст эчендә иярченле кушма җөмләләрне танып белү һәм аларга синтаксик анализ ясау. | 11.12 | |
| 29 | **СҮ. Кушма җөмләдә тыныш билгеләре куюга изложение язарга әзерләнү** | Сөйләм үстерү | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, изложение язу үз сөйләмеңнең, төзегән текстларныың дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, караламада язма сөйләм төзү; язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Текстка якын язма сөйләм төзү | 15.12 | |
| 30 | **СҮ. Кушма җөмләдә тыныш билгеләре куюга иҗади изложение язу** | Сөйләм үстерү | Телдән һәм язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү | План нигезендә изложение язу, төзегән текстның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Изложение | 18.12 | |
| | **Стилистика һәс сөйләм культурасы - 16** | | | | | | |
| 31 | Әдәби сөйләм, аның стильләре. Стилистика. | Яңа белемнәр бирү | Билгеле бер телдә сөйләшүче кешеләрнең фикерне аңлаешлы итеп һәм гасырлар буена урнашып килгән таләпләрне бозмыйча, төгәл итеп сөйләүләренә әдәби сөйләм | Укытучы сөйләме, конспектлау күнекмәләре бирү. Таблица ясау. Стилистика һәм сөйләм культурасы → Сөйләм стильләре → Күнегүләр. | Дәреслектәге теоретик материал буенча сорауларга җавап | 22.12 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | дип әйтүне, телдәге стильләрне өйрәнә торган фәннең стилистика дип аталуын белү. | | | | |
| 32 | **СҮ. Конспект һәм тезис турында төшенчә. Текстны конспектлау күнекмәләре бирү.Тезислы һәм тулы конспект.** | Сөйләм үстерү | Конспект һәм тезис, тезислы конспект турында төшенчә, аларның тормышта әһәмияте. Текстны конспектлау күнекмәләре бирү. | Тезислы һәм тулы конспект төзи белү | Конспект | 25.12 | |
| **3 нче чирек** | | | | | | | |
| 33 | Әдәби стильнең лексик һәм грамматик үзенчәлекләре | Катнаш | Сөйләм стиленең төрләре һәм үзенчәлекләре турында тулы күзаллау булу. Әдәби стиль турында аңлата белү. Әдәби стильдә барлык әдәби әсәрләрнең язылуын аңлау һәм аңлата белү. | Дәреслек белән эшләү күнекмәләре. Мөстәкыйль рәвештә таблица тутыру. Өзекләрне укып, аларның кайсы стильгә каравын һәм нинди лексик, синтаксик үзенчәлекләргә ия булуын ачыклау. | Таблица тутыру | 12.01 | |
| 34 | Публицистик һәм фәнни стильләр, аларның лексик һәм грамматик үзенчәлекләре | Катнаш | Публицистик стильдә газета-журнал мәкаләләре, тәнкыйть материаллары, һәртөрле өндәмәләр, юлъязмалар, очерк, фельетоннарның иҗат ителүен белү. Фәнни стильдә гыйльми мәкалә, китаплар, белешмә, дәреслекләр, диссертацияләр язылуын, аның башка стильдән махсус фәнни терминнарның күбрәк кулланылуы, сүзләрнең | Дәреслек белән эшләү күнекмәләре. Мөстәкыйль рәвештә таблица тутыру. Өзекләрне укып, аларның публицистик стильгә каравын һәм нинди лексик, синтаксик үзенчәлекләргә ия булуын ачыклау. Өзекләр китерү. Өзекләрне укып, аларның фәнни стильгә каравын һәм нинди лексик, синтаксик үзенчәлекләргә ия булуын ачыклау. Аерым стильгә караган | Таблица тутыру | 15.01 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | туры, төгәл мәгънәсендә бирелүе белән аерылып торуын белү. Фәнни текстларның конспектын яза алу. | өзекләр китерү. ИР белән эшләү: “Таткнигофонд” сайтында (http://www.tatknigafund.ru/) теркәлү һәм фәнни мәкаләнең конспектын ясау күнегүләре | | | |
| 35 | Рәсми һәм сөйләмә стильләр, аларның лексик һәм грамматик үзенчәлекләре | Катнаш | Рәсми стильдә юридик эш кәгазьләре язылуын белү. Үтенеч һәм ышаныч кәгазен мөстәкыйль рәвештә яза белү. Сөйләмә стильнең әдәби тел нормаларын үзләштергән кешеләрнең көндәлек аралашулары вакытында кулланылуын белү. | Дәреслек белән эшләү күнекмәләре. Мөстәкыйль рәвештә таблица тутыру. Өзекләрне укып, аларның рәсми стильгә каравын һәм нинди лексик, синтаксик үзенчәлекләргә ия булуын ачыклау. Аерым стильгә караган өзекләр китерү. | Таблица тутыру | 19.01 | |
| 36 | Эпистоляр стиль, аның телебез һәм әдәбиятыбыз тарихында тоткан урыны. | Катнаш | Эпистоляр стиль, аның телебез һәм әдәбиятыбыз тарихында тоткан урыны турында белешмә | Хатлар рәвешендә язылган әдәби әсәрләрдән хәбәрдар булу, аларны мисалга китерү. Хатлар аларның төрләре турында белү. | Хәбәрләшү хаты язу | 22.01 | |
| 37 | **СҮ. Ышанычнамә һәм шартнамә турында белешмә бирү, аларның тормышта әһәмиятен билгеләү, үрнәкләр төзү.** | Сөйләм үстерү | Эш кәгазьләре, аларга хас калыплар турында белемнәрен ныгыту | Ышанычнамә һәм шартнамәнең тормышта әһәмиятен белү Үрнәк нигезендә һәм мөстәкыйль рәвештә ышанычнамә һәм шартнамә яза белү | Ышанычнамә һәм шартнамә язу | 26.01 | |
| 38 | Синонимия. Морфологик һәм синтаксик синонимнар, аларны сөйләмдә куллану үзенчәлекләре | Катнаш | Төп мәгънәләре охшаш булган сүзләр, фразеологик әйләнмәләр, сүз формалары, сүзтезмәләр, җөмләләрнең синоним дип аталуын белү. Тулы синонимнар, | Синонимнарның төрләрен билгеләү. Нокталар урынына тиешле синонимнарны куеп язу. | Синонимнар сүзлеге белән эш | 29.01 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | стилистик синонимнар, мәгънәви синонимнар турында мәгълүматка ия булу. | | | | |
| 39 | Синонимия. Синтаксик синоним төрләре: сүзтезмәләрнең синонимлыгы, җөмлә кисәкләрен синонимик куллану, бер һәм ике составлы җөмләләрнең синонимлыгы, фигыль юнәлеше белән бәйле синонимлык, туры һәм кыек сөйләм синонимлыгы. | Катнаш | Синтаксик синоним төрләре: сүзтезмәләрнең синонимлыгы, җөмлә кисәкләрен синонимик куллану, бер һәм ике составлы җөмләләрнең синонимлыгы, фигыль юнәлеше белән бәйле синонимлык, туры һәм кыек сөйләм синонимлыгы турында белемнәр булу | Төрле төр күнегүләрдә синтаксик синонимнарны таба белү һәм төрен билгеләү | Язмача күнегүләр, телдән җаваплар | 02.02 | |
| 40 | Сөйләмдә синтаксик синонимнарны куллану. Аналитик һәм синтетик иярчен җөмләләрнең синонимлыгы, иярчен кисәк һәм иярчен җөмлә синонимлыгы. | Катнаш | Аналитик һәм синтетик иярчен җөмләләрнең синонимлыгы, иярчен кисәк һәм иярчен җөмлә синонимлыгы турында белемнәр булу | Төрле төр күнегүләрдә синтаксик синонимнарны таба белү һәм төрен билгеләү | Язмача күнегүләр, телдән җаваплар | 05.02 | |
| 41 | Сөйләмдә синтаксик синонимнарны куллану. Тезмә кушма җөмләләне синонимик куллану. | Катнаш | СИнтаксик синонимнар буенча белемнәрне гомумиләштерү һәм практик күнегүләр дә ныгыту | Төрле төр күнегүләрдә синтаксик синонимнарны таба белү һәм төрен билгеләү, өстәмә күнегүләр җыентыгы белән эшләү | Мөстәкыйль эш | 09.02 | |
| 42 | **СҮ. Текст, тема, төп уй төшенчәсе бирү. Сочинениегә материал туплау, төрле төр әдәби әсәрләрне сочинениедә куллана белү.** | Сөйләм үстерү | Үз күзәтүләреңнән чыгып, язма сөйләм төзү төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүматны таба белү | Язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү, сөйләмдә үәзерге татар әдәби теленең орфоэпик, лексик һәм грамматик | Материал туплау, караламада язу | 12.02 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нормаларын үтәү, язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | | | |
| 43 | **СҮ. Ирекле темага контроль сочинение язу** | Сөйләм үстерү | Язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү | План нигезендә туплаган материалны эзлекле урнаштырып язма сөйләм төзү, төзегән текстның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Контроль сочинение | 16.02 | |
| 44 | Лексик һәм грамматик калькалар турында төшенчә бирү. Бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүнең үзенчәлекләре. | Яңа белемнәр бирү | Лексик һәм грамматик калькалар турында мәгълүматка ия булу, аларның татар сөйләмендә кулланылышын белү.Бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүнең үзенчәлекләре турында белемнәр булу | Бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә аермаларны кулланып тәрҗемә итә белү. Рус теленнән татар теленә, татар теленнән рус теленә тәр җемә итүгә күнегүләр эшләү | Тәрҗемә итүгә корылган иҗади бирем | 19.02 | |
| 45 | Синтаксик калькаларны татар сөйләмендә дөрес куллану. | Ныгыту | Татар телендә рус теленнән урнашып калган калькалар турында белемнәр булу, аларны дөрес куөллана белү, дөрес кулланмауның татар теле саылыгына тискәре тәэсирен белү | Бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә аермаларны кулланып тәрҗемә итә белү. Рус теленнән татар теленә, татар теленнән рус теленә тәр җемә итүгә күнегүләр эшләү | Тәрҗемә итүгә корылган иҗади бирем | 26.02 | |
| 46 | Сөйләм культурасы, аның төп нигезләре турында белешмә бирү. | Яңа белемнәр бирү | Сөйләм культурасының кешедә культураның бер билгесе булуын аңлау. | Укытучы сөйләме, дәреслек белән эшләү,конспектлау күнекмәләре. | Конспект | 02.03 | |
| 47 | Сөйләм төгәл һәм аңлаешлы булсын. | Катнаш | Сөйләм төгәл булсын өчен, һәр сүзнең җөмләдәге үз | Синонимнарны искә төшереү, аларның | Сөйләм төгәлсезлеге | 05.03 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | урынын ачык күзаллау кирәклеген белү, сөйләм аңлаешлы булсын өчен, җөмләнең төзек булуын, кабатлауларның булмавын, туган тел үзенчәлекләрен искә алу кирәклеген аңлау. | кирәклесен сайлап җөмләләрне үзгәртүгә, ияртүче сүзгә карап җөмләдәге сүз тәртибен үзгәртүгә күнегүләр эшләү; Синонимнарның төп мәгънәләрен һәм мәгънә аерымлыкларын билгеләү. | киткән җөмләләрне төзәтүгә күнегүләр | | |
| 48 | Сөйләм саф булсын | Катнаш | Сөйләм сафлыгына ирешү өчен, туган телне, аның байлыгын яхшы үзләштерү һәм шул байлыктан, гаҗәеп зур һөм кыйммәтле хәзинәдән оста һәм сак файдалана белү кирәклеген белү. Төрле чорда әдипләрнең сөйләм сафлыгы өчен көрәшүләре, аларның төрле жанрдагы әсәрләреннән өзекләр белән танышу; үз сөйләмеңә һәвакыт игътибарлы булырга кирәклеген аңлау | Укытучы сөйләме, конспектлау күнекмәләре. Өзек ләрне укып, сөйләм сафлыгына зыян китерә, боза торган сүзләрне таба белү, авторның нинди максат белән бу рәвешле язуын аңлату. | Сөйләм төгәлсезлеге киткән җөмләләрне төзәтүгә күнегүләр | 12.03 | |
| 49 | Сөйләм җыйнак һәм аһәңле булсын | Катнаш | Сөйләм аңлаешлы булсын өчен, җөмләнең төзек булуын, кабатлауларның булмавын, туган тел үзенчәлекләрен искә алуны, укучыны җәлеп итәр өчен, сөйләмнең аһәңле, матур яңгырашлы булырга тиешлеген белү | Җөмләләрне җыйнаклык таләбеннән чыгып үзгәртеп язу. Стилистика һәм сөйләм культурасы → Әдәби сөйләмгә куелган таләпләр схемасы буенча эшләү. Аһәңнең бозылуы сөйләмдәге аерым өлешләрнең кимчелегеннән җыелуын тикшерү. Вакытлы матбугат белән | Сөйләм төгәлсезлеге киткән җөмләләрне төзәтүгә күнегүләр | 16.03 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | эшләү | | | |
| 50 | “Сөйләм культурасы” темасы буенча күнегүләр эшләү. Бирелгән җөмләләрне сөйләм культурасы таләпләре буенча төзәтү күнекмәләрен ныгыту. | Ныгыту | Бирелгән җөмләләрне сөйләм культурасы таләпләре буенча төзәтү күнекмәләрен ныгыта белү, үз сөйләмеңә һәвакыт игътибарлы булырга кирәклеген онытмау. | Бирелгән җөмләләрне сөйләм культурасы таләпләре буенча төзәтү | Презентация | 19.03 | |
| 51 | **СҮ. “Сөйләм культурасы” темасы буенча сочинениегә әзерлек. (“Татарстан-туган илем”)** | Сөйләм үстерү | Үз күзәтүләреңнән чыгып, язма сөйләм төзү төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүматны таба белү | Язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү, сөйләмдә үзерге татар әдәби теленең орфоэпик, лексик һәм грамматик нормаларын үтәү, язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Материал туплау, караламада язу | 19.03 | |
| **4 нче чирек** | | | | | | | |
| 52 | **СҮ. “Сөйләм культурасы” темасы буенча сочинение язу** | Сөйләм үстерү | Язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү | План нигезендә туплаган материалны эзлекле урнаштырып язма сөйләм төзү, төзегән текстның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Сочинение | 02.04 | |
| | **Кабатлау һәм бердәм республика тестына әзерлек - 6** | | | | | | |
| 53 | Хаталар өстендә эш. Бердәм республика тестына әзерлек. | Ныгыту | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. | КҮМның А һәм В вариантлары буенча мөстәкыйль эшләү. | Тест | 06.04 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 54 | Хаталар өстендә эш. Бердәм республика тесты.(ЕРТ) | | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. | КҮМның А һәм В вариантлары буенча мөстәкыйль эшләү. | Тест | 09.04 | |
| 55 | “Фонетика” бүлеге буенча кабатлау күнегүләре | Кабатлау | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. | КҮМның А һәм В вариантлары буенча мөстәкыйль эшләү. | Тест | 13.04 | |
| 56 | “Лексика” бүлеге буенча кабатлау күнегүләре | Кабатлау | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. | КҮМның А һәм В вариантлары буенча мөстәкыйль эшләү. | Тест | 16.04 | |
| 57 | "Морфология" бүлеге буенча кабатлау | Кабатлау | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. | КҮМның А һәм В вариантлары буенча мөстәкыйль эшләү. | Тест | 20.04 | |
| 58 | "Гади һәм кушма җөмлә синтаксисы" буенча кабатлау | Кабатлау | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. | КҮМның С варианты буенча мөстәкыйль эшләү. | Тест | 23.04 | |
| 59 | ***Арадаш аттестация. Грамматик биремле контроль диктант.*** | Белемнәрне бәяләү | Язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Дәрестә алган белемнәрне кулланып, грамоталы һәм чиста язу күнекмәсен камилләштерү. | К/диктант, грамматик бирем | 27.04 | |
| | **Тел турында гомуми мәгълүмат - 6** | | | | | | |
| 60 | Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат бирү. Телнең иҗтимагый әһәмияте. | Яңа белемнәр бирү | Милли телнең иҗтимагый тормыштагы әһәмиятен аңлау, телне саклау – милләтне саклауның төп өлеше икәнен үзләштерү. Кешеләрнең тормыш алып бару өчен матди һәм рухи яктан үзара төрле бәйләнешләргә керүен иҗтимагый мөнәсәбәтләр дип атау. | Дәреслек һәм өстәмә материал белән эшләү күнекмәләре | Сорауларга җавап | 30.04 | |
| 61 | Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләре. Тел һәм тарих, хәзерге милли татар | Яңа белемнәр бирү | Тел белән тарихның үзара мөнәсәбәтен ачык күзаллау. Хәзерге татар милли әдәби | Дәреслек һәм өстәмә материал белән эшләү күнекмәләре | Сорауларга җавап, таблица тутыру | 04.05 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | әдәби теленең тамырлары. Милли татар әдәби теленең формалашуы. | | теленең тамырларын һәм татар милли әдәби теленең ничек барлыкка килүен аңлау һәм аңлата белү. | | | | |
| 62 | Татар сөйләмә теленең төп диалектлары һәм аларның үзенчәлекләре турында белешмә бирү. | Яңа белемнәр бирү | Татар теленең диалектлары һәм сөйләшләре турында гомуми төшенчәгә ия булу: үзенчәлекле җирле сөйләмнең диалект дип аталуын, татар сөйләмә теленең өч зур диалекттан торуын, әлеге диалектларның үзенчәлеген белү. | Текстларда бирелгән язмаларның кайсы диалектка каравын билгеләү, бу диалектның әдәби әйтелештән аермаларын таба белү. | Текст белән эш, таблица тутыру | 07.05 | |
| 63 | Ике теллелек, аның төрләре. Татар әдәби теленең сафлыгын, аһәңен, матурлыгын, гаиләдә һәм мәктәптә тәрбияви көчен саклау.<br>“Татарстан халыклары телләре турында” ТР Законы | Яңа белемнәр бирү | Кемнең дә булса ике телдә сөйләшә, аңлаша алуының ике теллелек (билингвизм) дип аталуын, икенче телне тулы, камил яисә өлешчә генә белүенә карап, ике теллелекне тулы һәм өлешчә ике теллелеккә бүлүне белү.<br>“Татарстан халыклары телләре турында” ТР Законының төп эчтәлеген белү | Текстларны укып, татар-гарәп, татар-рус ике теллелеге йогынтысын аңлату.<br>“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законыннан өземтәләрне укып өйрәнү, кыскача эчтәлеген язу. | Сорауларга җавап | 11.05 | |
| 64 | **СҮ. Сочинение элементлары белән изложение язарга әзерләнү** | Сөйләм үстерү | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, изложение язу үз сөйләменңнең, төзегән текстларныың дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Текстның планын төзү, эчтәлеген сөйләү, караламада язма сөйләм төзү; язуда орфография һәм пунктуациянең төп кагыйдәләрен саклау | Текстка якын язма сөйләм төзү | 14.05 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 65 | **СҮ. Сочинение элементлары белән изложение язу.** | Сөйләм үстерү | Телдән һәм язма сөйләмдә үз фикереңне иркен рәвештә дөрес итеп, темага туры китереп, эзлекле һәм бәйләнешле итеп белдерү | План нигезендә изложение язу, төзегән текстның дөреслеген тикшерү, андагы грамматик һәм сөйләм хаталарын табып төзәтү | Изложение | 18.05 | |
| 66 | Тел гыйлеменең төп бүлекләре һәм әһәмияте | Катнаш | Тел гыйлеме - тел турындагы фән. Аның гомуми тел белемендә лингвистика дип йөртелүен, тел гыйлеменең төп тармакларын белү. | Дәреслек белән эшләү, теоретик материалны уку, терминнарны язып алу, теоретик материал һәм терминнар белән эшләү | Терминнарга аңлатма | 21.05 | |
| 67 | Хаталар өстендә эш. Эш кәгазьләре тарихы, аның төрләре буенча кабатлау. | Кабатлау | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. Диктантларга һәм грамматик биремгә анализ | Хаталар өстендә эшләү, бирелгән кагыйдәләргә мисаллар табу, дәлилләү | Хаталар өстендә эш | 25.05 | |
| 68 | Ел дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. **БРТ нәтиҗәләре** | Гомумиләштерү | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләренә ия булу. Диктантларга һәм грамматик биремгә анализ | Хаталар өстендә эшләү, бирелгән кагыйдәләргә мисаллар табу, дәлилләү | Хаталар өстендә эш | 25.05 | |

## Әдәбият

**1. Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы (6,7,10,32 статья).
3. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы №12138/13 хаты (07.09.2013), шул хатка әдәбият фәнен укыту буенча №12192/13 (09.09.2013) аңлатмасы;
4. “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа” (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: Г.Р.Галиуллина, М.М.Шәкүрова, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2013 ел.
5. Харисова Ч.М. Татар теле. Теория, күнегүләр, тестлар. – Казан: “Мәгариф”, 2006.
6. Максимов Н.В. Татар теленнән тестлар: Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: “Мәгариф”, 2008.
7. Бердәм руспублика имтиханына әзерләнү өчен ярдәмлек. Татар теле. – Казан: РИЦ “Школа”, 2008.
8. Татар теле. Бердәм республика имтиханына шзерлек өчен кулланма. – Казан: РИЦ “Школа”, 2007.
9. Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре. 8-11 сыйныфлар. – Казан: “Мәгариф”, 2005.
10. 5-11 нче сыйныфлар өчен диктантлар җыентыгы. - Казан: “Мәгариф”, 2001.
11. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М. Синтаксистан күнегүләр җыентыгы. - Казан: 1982.
12.Галиуллина Г.Р. Татар теле. Лексикология. - Казан: “Мәгариф”, 2007.
13.Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. - Казан: “Мәгариф”, 2006.
14.Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. - Казан: “Мәгариф”, 2002
15. Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы. 5-11 класслар - Казан: “Мәгариф”, 1998.
16. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теленнән күнегүләр җыентыгы һәм тестлар. – Казан: “Яңалиф”, 2006.
17.Максимов Н.В. Бердәм Республика имтиханы. Татар теленнән зачёт үткәрү өчен биремнәр. - Казан, 2007.
18.Татар телендә тыныш билгеләре. - Казан: “Мәгариф”,1995.
19.Мәктәптә татар телен укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004.
20.Вәлиева Ф.С.Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: “Раннур”, 2000.
21. Шәмсетдинова Р.Р. Татра теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.

**Тикшерү өчен:** Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү/Абдрәхимова Я.Х. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбендә эшләү че укытучылар өчен кулланма / Казан. «Мәгариф », 2007 ел

5-11 сыйныфлар өчен диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбендә эшләү че укытучылар өчен кулланма / Казан. «Мәгариф», 2001 ел

Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү/Абдрәхимова Я.Х. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбендә эшләү че укытучылар өчен кулланма / Казан. «Мәгариф », 2007 ел.

**2. Укыту-методик комплекс:**

| УМК | Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|---|
| **- Программа:** “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа” (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: Г.Р.Галиуллина, М.М.Шәкүрова, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2013 ел.<br>**- Дәреслек:** М.З.Зәкиев, С.М.Ибраһимовлар төзегән “Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныфы өчен татар теле дәреслеге” (Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2008 нче ел)- Диктантлар җыентыгы (төрле авторлар)<br>- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы №12138/13 хаты (07.09.2013), шул хатка әдәбият фәнен укыту буенча №12192/13 (09.09.2013) аңлатмасы;<br>- Изложениеләр җыентыгы (төрле авторлар)<br>- Н.В. Максимов.Татар теленнән тестлар,Казан, 2006 | 1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф.<br>Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы, К..: Раннур н-ты, 2000 ел.<br>2. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы. К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.<br>3. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2006.<br>4. Галлямов Ф.Г. Татар теле дәресләрендә синтаксик һәм пунктуацион анализ. Алабуга, 1996.<br>5. Гыймадиева Н., Нуруллина Р.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. К.: “Мәгариф”, 2007.<br>6. Максимов В.Н. Урта мәктәптә татар теле укыту. Фонетика. Морфология.К.: “Мәгариф” н-ты, 2004.<br>7. Максимов В.Н. Татар теленнән кулланма (синтаксис). Өченче китап. К.: “Мәгариф” н-ты, 2003.<br>8. Максимов В.Н. Урта мәктәптә татар теле укыту. Кушма җөмлә синтаксисы.<br>К.: “Мәгариф” н-ты, 2004.<br>9. Нигъматуллин М., Грамматик анализ. Алабуга, 2000.<br>10. Лингвистик анализ үрнәкләре.<br>11. Татар телендә тыныш билгеләре.<br>12. «Фән һәм мәктәп», «Мәгариф» журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары | 1. Лингвистик анализ үрнәкләре.<br>2. Татар телендә тыныш билгеләре.<br>3. Н.В. Максимов.Татар теленнән тестлар<br>4. Гыймадиева Н., Нуруллина Р.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. К.: “Мәгариф”, 2007.<br>5. Орфографик, орфоэпик һәм башка төр сүзлекләр |

## Укытуны матди-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү

Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләрендә ана теле предметын укытуның матди-техник һәм мәгълүмати нигезенә түбәндәгеләр кирә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән татар теле кабинеты;
- ана теле предметын өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары;
- компьютер программалары;
- укучыларының белемнәрен тикшерү текстлары, тестлар;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;

| **Укыту җиһазлары:** | **Электрон ресурслар һәм әдәбият** | **Интернет-ресурслар:** |
|---|---|---|
| 1.Басма материаллар, матбугат материаллары<br>2.Тарату тестлары<br>3. Сүзлекләр<br>4.матур әдәбият әсәрләре<br>5.Тематик папкаларда тупланган материаллар<br>6.Методик әдәбият<br>7.Язучылар иҗаты буенча материаллар | • Мультимедияле презентацияләр;<br>• ноутбук<br>• тема буенча текстлар һәм өстәмә материал<br>• интерактив биремнәр<br>• тест материаллары<br>• CD-дисклар; | http://gabdullatukay.ru/<br>http://mojahit.narod.ru/<br>http://gibrahimov.ucoz.ru/<br>http://alish.ru/<br>http://gzalilova.narod.ru/adabiyat_deftere/5kl.html |

**Укытуның электрон ресурслары:**

1. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы,Татар теле . 5-11// К.: Мәгариф, 2009
2. ТР МФМ, Милли мәгариф. Татар теле.// mon. tatar.ru
3. belem.ru; tatarile.org.com www.yandex. татар теле укытучыларының шәхси сайтлары